РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

Тел.:8(84364)2-63-02, факс:8(84364)2-63-04,e-mail:kukmor.kuk@tatar.ru,www:kukmor.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Карар**

«03» март, 2026 ел № 12

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетында Җирләү һәм күмү эше турында нигезләмә**

«Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законнары нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Җирләү һәм күмү эше турындагы нигезләмәне Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетына кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче: В.Н. Андреев

**ТР Кукмара муниципаль районы**
**Кукмара шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның « 03» мартындагы 12**
**номерлы карарына кушымта**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетында Җирләү һәм күмү эше турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Башкарма комитетында җирләү һәм күмү эше турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-8-ФЗ номерлы Федераль закон), «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнарның үлгәннәрне җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүгә хокуклары гарантияләре турында» Россия Федерациясе Президентының 1996 елның 29 июнендәге 1001 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Уставы нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күмү эшен һәм җирләүне оештыру тәртибен җайга сала.

1.2. Әлеге Нигезләмә максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

якын туганнары – турыдан-туры югарыга таба һәм түбәнгә таба линия буенча туганнар (ата-аналар һәм балалар, бабай, әби һәм оныклар), шулай ук эти-әниләре бер үк булган туганнар һәм бер уртак биологик ата-анасы булган туганнар (аталары яисә аналары уртак булган) абый-энеләр һәм апа-сеңелләр, уллыкка алынган балалары, уллыкка алучылары;

дини зират – бер конфессиягә караган үлгәннәрне яки һәлак булганнарны (алга таба – үлгәннәрне) тиешле дини йолаларны үтәп җирләү өчен билгеләнгән зират (җәмәгать зираты участогы);

җәмәгать зиратының хәрбиләр участогы – үлгән хәрбиләрне һәм аларга тиңләштерелгән категориядәге гражданнарны хәрбиләрчә күмү йоласын үтәп җирләү өчен билгеләнгән җәмәгать зираты участогы;

күмү зонасы – зиратның һәм (яисә) крематорийның җирләү гамәлгә ашырыла торган функциональ-территориаль зонасы;

катафалк белән ташулар – катафаль транспорт белән үлгәннәрнең мәетен яисә үлекне, күмү продукциясен һәм җирләүдә катнашучыларны ташу;

зират – үлгәннәрнең мәетен һәм көлен күмү өчен билгеләнгән җирләү билгеләнешендәге объект;

ирекле күмүләр өчен ябык зират – яңа күмү урыннары булдыру өчен территория тулысынча файдаланылган зират;

зират чоры – күмелгән гәүдәнең минеральләшүе төгәлләнә торган һәм туганнар күмелгән кабергә алга таба күмү рөхсәт ителә торган вакыт;

колумбарий – көлне яки көл салынган урналарны күмү өчен билгеләнгән бина, аның бер өлеше яки корылма;

мәетне яндыру – үлгән кешенең мәетен, биологик материалларны яндыру;

күмү урыны – җирләү билгеләнешендәге объект пространствосының үлгәннәрнең мәетен яисә көлен күмү өчен билгеләнгән өлеше;

җирләү урыны – этик, санитар һәм экологик таләпләргә ярашлы бүленгән, үлгән кешеләрнең гәүдәләрен (мәетен) күмү өчен булган зиратлар, үлгән кешеләрнең көле салынган (үлгән кешеләрнең гәүдәләрен (мәетен) яндырганнан соң калган көл салынган) урналарны күмү өчен булган кайгы диварлары, үлгән кешеләрнең гәүдәләрен (мәетен) утка ягу өчен булган крематорийлар, шулай ук үлгән кешеләрне күмү өчен билгеләнгән башка биналар һәм корылмалар корыла торган җир кишәрлекләре. Җирләү урыннары мәдәни-тарихи әһәмияткә ия объектларга керергә мөмкин;

минеральләшү – җирләнгән гәүдәнең аерым химик элементларга һәм гади химик кушылмаларга таркалу процессы;

кабер – җирдә, төрбәдә, колумбарийдан тыш, башка ритуаль корылмада җирләү өчен участокта урнашкан һәм үлгән кешенең мәетен табутта яки аннан башка яки көл салынган урналарны күмү өчен билгеләнгән урын;

кабер өстенә куела торган чардуган – кабер участогы периметры буенча урнаштырыла торган киртәләп торучы линияле корылма;

кабер өсте корылмасы – мемориаль мәгълүматны үз эченә алган, үлгәннәрнең истәлеген мәңгеләштерү өчен билгеләнгән һәм күмү урынында урнаштырыла торган архитектура-скульптура корылмасы (кабер ташы);

җәмәгать зираты – үлгәннәрне җирләү урыннары аларның исән чакта белдергән ихтыярын исәпкә алып йә күмү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт карары буенча каралган зират;

җирләү өчен билгеләнгән объект – халыкка ритуаль хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән шәһәр төзелеше яки архитектура комплексы, яки объект, территория яки участок (зират, крематорий, колумбарий һ. б.);

бер кешелек җирләү урыны – күмү билгеләнешендәге объект территориясендә бер үлгән кешене, шул исәптән, шәхесе Эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнмәгән кешене җирләү өчен бирелә торган участок;

җирләү – кеше үлеменнән соң аның гәүдәсен (мәетне) санитария һәм башка таләпләргә каршы килми торган гореф-гадәтләр һәм традицияләр нигезендә күмү буенча йола гамәлләре. Җирләү үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) җиргә (кабергә, склепка күмү), утка (мәетне яндыру һәм аннан соң көл салынган урнаны күмү), суга (Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә суга күмү) тапшыру юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин;

янәшә күмү – үлгән кешене билгеләнгән тәртиптә бирелгән, элек үлгән туганнарын җирләү башкарылган күмү урынында җирләү;

туганнар – якын туганнарыннан тыш, туганлык мөнәсәбәтләрендә торучы барлык башка затлар;

туганлык белән бәйле җирләү урыны – җирләү билгеләнешендәге объект территориясендә үлгән кешенең элек туганы күмелгән участок;

санитар-саклау зонасы – киңлеге Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән билгеләнә торган зират һәм (яисә) крематорий һәм торак (селитеб) яки сәнәгать төзелеше арасындагы функциональ-территориаль зона;

күмү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт – түләүсез җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеген күрсәтә торган җирле үзидарә органы тарафыннан төзелгән оешма;

күмү турында таныклык – күмү турында белешмәләр һәм күмү урыны өчен җаваплы зат булган һәм аның күмү урыныннан алга таба файдалану хокукын раслый торган документ;

мәетне кабердән казып алу – үлгән кешенең гәүдәсен, мәетен, суд-медицина яки криминалистик экспертиза өчен яки күчереп күмү өчен, кабердән казып алу.

## 2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ритуаль хезмәт күрсәтүләрне һәм күмү урыннарын карап тотуны оештыру өлкәсендә вәкаләтләр.

2.1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ритуаль хезмәт күрсәтүләрне һәм күмү урыннарын карап тотуны оештыру өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү һәм күмү эше өлкәсендә бердәм муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыру;

2) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү һәм күмү эше мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе

законнары, Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актлары таләпләренең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

3) җирләү һәм күмү эше өлкәсендә финанс, бюджет, инвестиция, бәя, тариф сәясәте һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең республика башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек;

4) җирләү һәм күмү эше мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актларны үз компетенциясе чикләрендә эшләү һәм кабул итү;

5) күмү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт – түләүсез җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеген күрсәтә торган җирле үзидарә органы тарафыннан төзелгән оешма;

6) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге җәмәгать зиратлары территориясендә башкарылган барлык күмүләрне исәпкә алып бару, шул исәптән күмүләрне теркәү кенәгәсен тутыру юлы белән;

7) җәмәгать зиратларында күмү зоналарын билгеләү һәм күмү (янәшә күмү) өчен урыннар бирү;

8) үлгән кешене җирләү өчен, зиратлар территорияләрендә түләүсез бирелә торган җир кишәрлеге зурлыгын билгеләү;

9) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать зиратларын ачу һәм ябу турында карарлар кабул итү;

10) яңа зиратлар төзү, гамәлдәге җәмәгать зиратларын киңәйтү, күчерү, ябу чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

11) зиратлардан һәм җирләү билгеләнешендәге башка объектлардан максатчан билгеләнеш буенча файдалануны тикшереп тору;

12) җирләү билгеләнешендәге объектларны саклауны оештыру;

13) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эшен оештыру торышына еллык мониторинг үткәрү;

14) җирләү эше мәсьәләләре буенча попечительлек (күзәтү) советлары төзү хокукы (аларны булдыру тәртибен һәм вәкаләтләрен билгеләп);

15) җирләү һәм җирләү эше өлкәсендәге мәсьәләләр буенча гражданнарга консультация бирү һәм килүчеләрне кабул итүне алып бару;

16) гамәлдәге законнар нигезендә башка вәкаләтләр.

## 3. Күмү урыннары

3.1. Җирләү урыны булып, этик, санитар һәм экологик таләпләргә ярашлы бүленгән, үлгән кешеләрнең гәүдәләрен (мәетен) күмү өчен булган зиратлар, үлгән кешеләрнең көле салынган (үлгән кешеләрнең гәүдәләрен (мәетен) яндырганнан соң калган көл салынган) урналарны күмү өчен булган кайгы диварлары, үлгән кешеләрнең гәүдәләрен (мәетен) утка ягу өчен булган крематорийлар, шулай ук үлгән кешеләрне күмү өчен билгеләнгән башка биналар һәм корылмалар корыла торган җир кишәрлекләре тора. Күмү урыннары мәдәни-тарихи әһәмияткә ия объектларга керергә мөмкин;

3.2. Күмү урыннарын булдыру турындагы карар гамәлдәге законнар таләпләре нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителә.

3.3. Корыла торган, шулай ук гамәлдәге күмү урыннары бетерелергә (сүтелергә) тиеш түгел һәм бары тик даими су басулар, җир убылу куркынычы янаганда, җир тетрәүләрдән һәм башка табигый бәла-казалардан соң, хәрби каберләрдән тыш, вәкаләтле орган карары белән генә күчерелә ала.

3.4. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге җәмәгать зиратлары ачык, ирекле күмү өчен ябык, ябык булырга мөмкин.

3.5. Җәмәгать зиратлары территориясендә түбәндәге күмү урыннары булырга мөмкин:

1) бер кешелек җирләү урыны;

2) туганы янына күмә торган;
3) дини;
4) шәрәфле;
5) хәрби.

3.6. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең җәмәгать зиратлары территориясендә хәрбиләрне күмү (хәрби участоклар), шәрәфле күмүләр һәм бер диндәге үлгәннәрне күмү өчен (дини участоклар) аерым җир кишәрлекләре (зоналар), шулай ук колумбарийлар каралырга мөмкин.

Зиратның хәрбиләр участокларында җирләү өчен, үлгән кешенең 8-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында күрсәтелгән гражданнар категориясенә каравын раслый торган документлар тапшырыла.

3.7. Күмү зонасы кварталларга һәм участокларга бүленә.

3.8. Үлгән кешенең гәүдәсе салынган табутны күмү өчен каберләр төзегәндә, кабер тирәнлеген җирле шартларга (грунт характерына һәм грунт сулары дәрәҗәсенә) карап билгеләргә кирәк. Шул ук вакытта кабернең озынлыгы 2 метрдан, киңлеге – 1 метр, тирәнлеге – 1,5 метрдан да ким булмаска тиеш. Барлык очракларда да кабер төбенең өслеге грунт сулары торышы дәрәҗәсеннән 0,5 метрга югарырак булырга тиеш.

3.9. Күмү урыннары җәмәгать зиратының билгеләнгән планлаштыруына туры китереп бирелә. Күмү урыннары арасындагы киңлек 0,5 метрдан ким була алмый.

3.10. Чардуган урнаштырганда, аның үлчәмнәре кабер өчен бүлеп бирелгән участокның норматив үлчәмнәренә туры килергә тиеш. Чардуганның биеклеге 0,75 метрдан артмаска тиеш. Кабер ташы корылмасының биеклеге 1,2 метрдан артмаска тиеш.

3.11. Зиратның билгеләнгән планлаштыруын бозып, шул исәптән күмү урыннары арасында, юл кырыйларында һәм санитар-яклау зонасы чикләрендә күмү урыннарын урнаштыру рөхсәт ителми.

## 4. Бер кешелек җирләү урыннары

4.1. Бер кешелек җирләү урыны вәкаләтле орган тарафыннан түләүсез нигездә бирелә.

4.2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә бер кешелек җирләүгә бушлай бирелә торган җир кишәрлегенең күләме 7,5 кв. м (2,5 м х 3 м) (2,2 м тирәнлек) тәшкил итә.

4.3. Бер кешелек җирләү урыны бирү турындагы гариза үлгән кешенең ире (хатыны), якын туганнары, бүтән туганнары яисә законлы вәкилләре тарафыннан, ә андыйлар булмаганда, үлгән кешене җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлар (алга таба – гариза бирүче) тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдә тапшырыла.

4.4. Бер кешелек җирләү урыны бирү турындагы гаризага түбәндәге документлар кушып бирелә:

1) гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәсен кушып);

2) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, әгәр бер кешелек җирләү урыны бирү турында гариза белән гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать итсә, шулай ук гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

3) үлем турында таныклык күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәсен кушып);

4) мәетне яндыру турындагы белешмәнең күчермәсе – көл салынган урнаны күмгәндә (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

5) ГХАТ органнары тарафыннан бирелгән, үле бала туган очракта, үле бала тууны дәүләт теркәвенә алу фактын раслый торган документ.

6) шәхесе Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вакытларда билгеләнмәгән үлгән кешене җирләүгә Эчке эшләр органнарының ризалыгын раслый торган документ.

7) гариза бирүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы.

4.5. Бер кешелек җирләү урыны бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып:

1) соратыла торган зират күмү өчен ябык;

2) гаризаны карау өчен кирәкле документларның төп нөсхәләрен тапшырмау;

3) тапшырылган документларда чынбарлыгына объектив рәвештә инануны кыенлаштыра торган тулы булмаган, бозып күрсәтелгән яисә дөрес булмаган мәгълүмат булу.

4.6. Бер кешелек җирләү урыны бирүдән баш тарту өчен нигезләр булганда, вәкаләтле орган, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, бер кешелек җирләү урыны бирүдән дәлилләнгән баш тартуны рәсмиләштерә.

4.7. Бер кешелек җирләү урыны бирүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, вәкаләтле орган түбәндәгеләрне башкара:

гариза бирүче белән бергә күзалланган күмү урынының җир кишәрлеген бүлеп бирү максатларында зиратны тикшерә;

бер кешелек җирләү урыны бирү турында карар рәсмиләштерә; күмү урынын күмүләрне теркәү кенәгәсендә терки.

4.8. Бер кешелек җирләү урыны бирү турындагы яисә бер кешелек җирләү урыны бирүдән баш тарту турындагы карар вәкаләтле орган тарафыннан гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне кабул ителә.

4.9. Бер кешелек җирләү урыны бирү яисә бер кешелек җирләү урыны бирүдән баш тарту турындагы карар гариза бирүчегә шәхсән кәгазь чыганактагы документ рәвешендә бирелә.

## 5. Туганнарны күмү

5.1. Туганлык белән бәйле җирләү урыны вәкаләтле орган тарафыннан түләүсез нигездә бирелә.

5.2. Туганнарны күмү урыннары ир белән хатынны, якын туганнарны һәм башка туганнарны күмү мөмкинлеген исәпкә алып бирелә.

5.3. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә туганлык белән бәйле җирләү урыны өчен бушлай бирелә торган җир кишәрлегенең күләме 7,5 кв. м (2,5 м х 3 м) (2,2 м тирәнлек) тәшкил итә.

5.4. Туганлык белән бәйле җирләү урыны бирү турындагы гариза гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдә тапшырыла.

5.5. Туганлык белән бәйле җирләү урыны бирү турындагы гаризага түбәндәге документлар кушып бирелә:

1) гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәсен кушып);

2) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, әгәр туганлык белән бәйле җирләү урыны бирү турында гариза белән гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать итсә, шулай ук гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

3) үлем турында таныклык күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәсен кушып);

4) мәетне яндыру турындагы белешмәнең күчермәсе – көл салынган урнаны күмгәндә (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

5) ГХАТ органнары тарафыннан бирелгән, үле бала туган очракта, үле бала тууны дәүләт теркәвенә алу фактын раслый торган документ.

6) гариза бирүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы.

5.6. Гаризаны карау, туганлык белән бәйле җирләү урыны бирү турында яисә туганлык белән бәйле җирләү урыны бирүдән баш тарту турында карар кабул итү әлеге Нигезләмәнең 4.5-4.9 пунктларында билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителә.

## 6. Шәрәфле күмүләр

6.1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең җәмәгать зиратлары территориясендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге алдында аерым казанышлары булган үлгән кешеләрне җирләү өчен шәрәфле җирләү участоклары (зоналар) булдырылырга мөмкин.

6.2. Шәрәфле күмү урыны вәкаләтле орган тарафыннан түләүсез нигездә бирелә.

6.3. Шәрәфле күмү урыннарында түбәндәге категория гражданнарны җирләү гамәлгә ашырыла:

1) Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе Геройлары;

2) Социалистик Хезмәт Геройлары;

3) Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары;

4) I, II һәм III дәрәҗә Дан орденнары белән бүләкләнүчеләр, Дан орденының тулы кавалерлары;

5) I, II һәм III дәрәҗә Хезмәт Даны орденнары белән бүләкләнүчеләр, Хезмәт Даны орденының тулы кавалерлары;

6) Бөек Ватан сугышы ветераннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар;

7) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегенең шәрәфле гражданнары;

8) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге үсешенә өлеш керткән предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләре.

6.4. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә шәрәфле күмү өчен бушлай бирелә торган җир кишәрлегенең күләме 7,5 кв. м (2,5 м х 3 м) (2,2 м тирәнлек) тәшкил итә.

6.5. Шәрәфле күмү өчен урын бирү турындагы гариза гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдә тапшырыла.

6.6. Шәрәфле күмү урыны бирү турындагы гаризага түбәндәге документлар кушып бирелә:

1) гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәсен кушып);

2) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, әгәр шәрәфле җирләү өчен урын бирү турында гариза белән гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать итсә, шулай ук гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

3) үлгән кешенең Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге алдындагы тиешле казанышларын раслый торган документлар (хезмәт кенәгәләренең (булган очракта) яисә хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеген раслый торган башка документларның күчермәләре, таныклыклар һәм бүләкләрнең төп нөсхәләре);

4) үлем турында таныклык күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәсен кушып);

5) мәетне яндыру турындагы белешмәнең күчермәсе – көл салынган урнаны күмгәндә (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

6) гариза бирүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы.

6.7. Гаризаны карау, шәрәфле җирләү өчен урын бирү турында яисә шәрәфле җирләү өчен урын бирүдән баш тарту турында карар кабул итү әлеге Нигезләмәнең 4.5-4.9 пунктларында билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителә.

## 7. Хәрбиләр каберләре

7.1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының җәмәгать зиратлары территориясендә хәрбиләрне күмү өчен аерымланган җир кишәрлекләре (зоналар) (хәрби кишәрлекләр) каралырга мөмкин.

7.2. Хәрбиләрчә күмү урыны вәкаләтле орган тарафыннан түләүсез нигездә бирелә.

7.3. Үлгән кешенең белдергән ихтыярын йә иренең, якын туганнарының яисә башка туганнарының теләген исәпкә алып, 8-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы 1 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән мәетләрне хәрби участокларда җирләү рөхсәт ителә.

7.4. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә хәрби күмү өчен бушлай бирелә торган җир кишәрлегенең күләме 20,0 кв. м (4,0 м х 5,0 м) (2,2 м тирәнлек) тәшкил итә.

7.5. Хәрби күмү өчен урын бирү турындагы гариза гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдә тапшырыла.

7.6. Хәрбиләр каберлеге өчен урын бирү турындагы гаризага түбәндәге документлар кушып бирелә:

1) гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәсен кушып);

2) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, әгәр хәрби җирләү өчен урын бирү турында гариза белән гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать итсә, шулай ук гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

3) үлем турында таныклык күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәсен кушып);

4) мәетне яндыру турындагы белешмәнең күчермәсе – көл салынган урнаны күмгәндә (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

5) үлгән кешенең җәмәгать зиратының хәрбиләр кишәрлегендә күмелергә мөмкин затлар категориясенә керүен раслый торган документлар.

6) гариза бирүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы.

7.7. Гаризаны карау, шәрәфле җирләү өчен урын бирү турында яисә шәрәфле җирләү өчен урын бирүдән баш тарту турында карар кабул итү әлеге Нигезләмәнең 4.5-4.9 пунктларында билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителә.

8. Янәшә күмү

8.1. Булган кабергә янәшә күмү, буш урын булганда, санитария нормаларын үтәп башкарыла. Күмгәндә табутлар арасындагы ара (табут белән урна арасында, урна белән урна арасында) вертикаль һәм горизонталь буенча 0,5 м дан ким булмаска тиеш, һәм ул җир катламы белән тутырыла. Табутларның өске тигезлегеннән алып җир өслегенә кадәр җир катламының калынлыгы 1 метрдан да ким булмаска тиеш.

8.2. Янәшә күмү бары тик минеральләшү чоры узгач кына башкарыла, әмма соңгы күмү вакытыннан 15 елдан да иртәрәк түгел.

Мәетне яндырганнан соң көл салынган урнаны янәшә күмү соңгы күмү вакытыннан узган вакытка бәйсез рәвештә башкарыла.

8.3. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендәге зиратларда туганлык белән бәйле, шәрәфле, хәрбиләрне күмү урынында янәшә күмүгә рөхсәт бирү түләүсез нигездә гамәлгә ашырыла.

8.4. Янәшә күмүгә рөхсәт бирү турында гариза гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә турыдан-туры вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткәндә тапшырыла.

8.5. Янәшә күмүгә рөхсәт бирү турындагы гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) күмү турында таныклык (күмү турында таныклык булмаган очракта, вәкаләтле орган күмүләрне теркәү кенәгәсендә аның исеменә күмү урыны теркәлгән зат турында белешмәләрнең булуын билгели);

2) гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәсен кушып);

3) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, әгәр янәшә күмү өчен рөхсәт бирүне сорап гариза белән гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать итсә, шулай ук гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

4) үлем турында таныклык күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәсен кушып);

5) ГХАТ органнары тарафыннан бирелгән, үле бала туган очракта, үле бала тууны дәүләт теркәвенә алу фактын раслый торган документ;

6) мәетне яндыру турындагы белешмәнең күчермәсе – көл салынган урнаны күмгәндә (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

7) үлгән кешенең исеменә күмү урыны теркәлгән зат белән (яисә тиешле күмү урынында күмелгән зат белән) туганлык бәйләнешен раслый документлар йә үлгән кешене күмүгә аның язма ризалыгын раслый торган документлар;

8) гариза бирүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы.

Аның исеменә күмү урыны теркәлгән зат үлгән очракта, янәшә күмүгә рөхсәт бирү турындагы гаризага шулай ук түбәндәгеләр теркәлә:

1) үлгән кеше исеменә рәсмиләштерелгән күмү турында таныклык (күмү турында таныклык булмаган очракта, вәкаләтле орган күмүләрне теркәү кенәгәсендә аның исеменә күмү урыны теркәлгән зат турында белешмәләрнең булуын билгели);

2) аның исеменә күмү урыны теркәлгән затның үлү турында таныклыгы күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

3) мәетне яндыру турындагы белешмәнең күчермәсе – көл салынган урнаны күмгәндә (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

8.6. Янәшә күмүгә рөхсәт бирүдән баш тарту өчен, түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) соратылган кирәкле күмү урынында әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән бер кешелек кабер үлчәменнән чыгып, табут белән янәшә күмү өчен буш урын булмау;

2) соратыла торган зират күмү өчен ябык;

3) гаризаны карау өчен кирәкле документларның төп нөсхәләрен тапшырмау;

4) тапшырылган документларда чынбарлыгына объектив рәвештә инануны кыенлаштыра торган тулы булмаган, бозып күрсәтелгән яисә дөрес булмаган мәгълүмат булу;

5) минеральләшү чоры тәмамланмаган, көл салынган урнаны кабергә янәшә күмүдән тыш (табутка табут белән янәшә күмгәндә);

6) үлгән кешене янәшә күмүгә рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта (үлгән кеше исеменә рәсмиләштерелгән күмү турында таныклык булмаганда), күмүләрне теркәү кенәгәсендә үлгән кеше исеменә күмү урынын теркәү турында белешмәләрнең булмавы.

8.7. Гаризаны карау, янәшә күмү өчен урын бирү турында яисә янәшә күмү өчен урын бирүдән баш тарту турында карар кабул итү әлеге Нигезләмәнең 4.5 – 4.9 пунктларында билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителә.

## 9. Үлгән кешенең мәетен (үлекне) алга таба күчереп күмү өчен казып алу

9.1. Күчереп күмү максатыннан, күмелгән кешенең мәетен кабердән казып алу санитария нормалары һәм кагыйдәләре таләпләрен исәпкә алып башкарыла.

9.2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан зиратта җирләнгән үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алуга рөхсәт бирү түләүсез нигездә башкарыла.

9.3. Үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алуга рөхсәт бирү турында гариза гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә, турыдан-туры вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткәндә тапшырыла.

9.4. Үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алуга рөхсәт бирү турындагы гаризага түбәндәге документлар кушып бирелә:

1) күмү турында таныклык (күмү турында таныклык булмаган очракта, вәкаләтле орган күмүләрне теркәү кенәгәсендә аның исеменә күмү урыны теркәлгән зат турында белешмәләрнең булуын билгели);

2) гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәсен кушып);

3) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, әгәр үлгән кешенең мәетен (үлекне) алга таба күчереп күмү өчен казып алу турындагы гариза белән гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать итсә, шулай ук гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

4) үлем турында таныклык күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәсен кушып);

5) ГХАТ органнары тарафыннан бирелгән, үле бала туган очракта, үле бала тууны дәүләт теркәвенә алу фактын раслый торган документ;

6) мәетне яндыру турындагы белешмәнең күчермәсе – көл салынган урнаны күмгәндә (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

7) үлгән кешенең казып алынган мәетен (үлекне) күчереп күмү урыны булуын раслый торган документ;

8) тиешле күмү урынына җирләнгән үлгән кеше белән туганлык бәйләнешен раслый торган документлар яисә әлеге документларның нотариаль таныкланган күчермәләре;

9) СЭС (РосСанЭпидНадзор) рөхсәте: мәрхүмнең мәетен кабердән казып алуга һәм транспорт белән күчерүгә белешмә;

10) кеше үлеменең җинаять-җәзага тартыла торган гамәлләр белән бәйле булмавы турында хокук саклау органнары (полиция) белешмәсе.

11) гариза бирүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы.

9.5. Үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алуга рөхсәт бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) гаризаны карау өчен кирәкле документларның төп нөсхәләрен тапшырмау;

2) тапшырылган документларда чынбарлыгына объектив рәвештә ышануны кыенлаштыра торган тулы булмаган, бозып күрсәтелгән яисә дөрес булмаган мәгълүмат булу;

3) күмүләрне теркәү кенәгәсендә үлгән кешенең исеменә күмү урынын теркәү турында белешмәләрнең булмавы (күмү турында таныклык булмаганда).

9.6. Үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алуга рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигезләр булганда, вәкаләтле орган, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алуга рөхсәт бирүдән дәлилләнгән баш тартуны рәсмиләштерә.

9.7. Үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алуга рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, вәкаләтле орган түбәндәгеләрне башкара:

үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алуга рөхсәт рәсмиләштерә;

күмүләрне теркәү кенәгәсенә күчереп күмү турында тиешле язманы кертә (бер үк вакытта үлгән кешенең мәете (үлекне) казып алынган күмү урынында җирләү турындагы язманы гамәлдән чыгара).

үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алу буенча чаралар оештыра.

9.8. Үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алуга рөхсәт бирү турында яисә үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алуга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар вәкаләтле орган тарафыннан гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне кабул ителә.

9.9. Үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алуга рөхсәт бирү турында яисә үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алуга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар гариза бирүчегә шәхсән кәгазьдәге документ рәвешендә бирелә.

9.10. Үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алу эшләре санитария кагыйдәләрен үтәп башкарылырга тиеш.

Үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алу эшләре тәмамлангач, үлгән кешенең калдыкларын мәетен (үлекне) казып алу турында ике нөсхәдә акт төзелә, анда үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алу эшләренең башлану һәм тәмамлану урыны, датасы һәм вакыты, аның исеменә күмү урыны теркәлгән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) күрсәтелә.

Үлгән кешенең мәетен (үлекне) казып алу турындагы актның беренче нөсхәсе вәкаләтле органда саклана, актның икенче нөсхәсе күмү урыны теркәлгән затка кул куйдырып тапшырыла.

9.11. Күмү урынында бер генә үлгән кешенең мәете (үлек) күмелгән очракта, күмү турында таныклык кире алына.

## 10. Күмү урыннарын теркәү (яңадан теркәү)

10.1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендәге җәмәгать зираты территориясендә башкарылган һәр күмү вәкаләтле орган тарафыннан күмүләрне теркәү кенәгәсендә теркәлә.

10.2. Күмү урынын яңадан теркәү аның исеменә күмү урыны теркәлгән зат үлгән очракта вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла һәм мөрәҗәгать итү характерында була.

Күмү урыннарын яңадан теркәү өчен түләү алынмый.

10.3. Күмү өчен урынны яңадан теркәү турындагы гариза гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдә тапшырыла.

10.4. Күмү урынын яңадан теркәү турындагы гаризага түбәндәге документлар кушып бирелә:

1) күмү турында таныклык (күмү турында таныклык булмаган очракта, махсуслаштырылган хезмәт күмүләрне теркәү кенәгәсендә аның исеменә күмү урыны теркәлгән зат турында белешмәләрнең булуын билгели);

2) гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәсен кушып);

3) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, әгәр күмү урынын яңадан теркәү турында гариза белән гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать итсә, шулай ук гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

4) күмү урынын аның исеменә яңадан теркәү гамәлгә ашырыла торган затның шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

5) аның исеменә күмү урынын яңадан теркәү гамәлгә ашырыла торган зат вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, шулай ук аның исеменә күмү урынын яңадан теркәү гамәлгә ашырыла торган зат вәкиленең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

6) аның исеменә күмү урыны теркәлгән затның үлеме турында таныклык яисә аның нотариаль таныкланган күчермәсе (күмү урыны аның исеменә теркәлгән зат үлгән очракта);

7) күмү урыны теркәлгән затның күмү урыны яңадан теркәлә торган зат белән йә тиешле күмү урынында күмелгән зат белән туганлык бәйләнешен раслый торган документлар яисә әлеге документларның нотариаль таныкланган күчермәләре.

10.5. Күмү урынын яңадан теркәүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) гаризаны карау өчен кирәкле документларның төп нөсхәләрен тапшырмау;

2) тапшырылган документларда чынбарлыгына объектив рәвештә inануны кыенлаштыра торган тулы булмаган, бозып күрсәтелгән яисә дөрес булмаган мәгълүмат булу;

3) күмү урынын яңадан теркәү аның исеменә гамәлгә ашырыла торган зат гариза биргән очракта (күмү турында таныклык булмаганда), күмүләрне теркәү кенәгәсендә үлгән кеше исеменә күмү урынын теркәү турында белешмәләрнең булмавы.

10.6. Күмү урынын яңадан теркәүдән баш тарту өчен нигезләр булганда, вәкаләтле орган, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, күмү урынын яңадан теркәүдән баш тартуны дәлилләп рәсмиләштерә.

10.7. Күмү урынын яңадан теркәүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, вәкаләтле орган түбәндәгеләрне башкара:

күмү урынын яңадан теркәү турында карар рәсмиләштерә;

күмүләрне теркәү кенәгәсенә тиешле язманы кертә.

10.8. Күмү урынын яңадан теркәү турындагы яисә күмү урынын яңадан теркәүдән баш тарту турындагы карар вәкаләтле орган тарафыннан гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне кабул ителә.

10.9. Күмү урынын яңадан теркәү турындагы яисә күмү урынын яңадан теркәүдән баш тарту турындагы карар гариза бирүчегә шәхсән кәгазь чыганактагы документ рәвешендә бирелә.

10.10. Күмү урыны аның исеменә яңадан теркәлгән затка вәкаләтле орган тарафыннан күмү турында таныклык бирелә.

## 11. Күмү турында таныклыклар рәсмиләштерү

11.1. Күмү көнендә вәкаләтле орган тарафыннан тиешле күмү турында таныклык төзелә һәм бирелә.

11.2. Күмүләр турында таныклыкларны, шул исәптән әлеге Нигезләмә кабул ителгәнче башкарылганнарын да рәсмиләштерү вәкаләтле орган тарафыннан түләүсез нигездә гамәлгә ашырыла.

11.3. Күмү турында таныклыкта түбәндәгеләр күрсәтелә:

территориясендә күмү урыны булдырылган җәмәгать зираты исеме;

зиратның урнашу урыны (адресы);

җирләү төре (бер кешелек, туганлык белән бәйле, дини, шәрәфле, хәрбиләрчә);

кабернең үлчәме;

зиратта күмү урынының урнашкан җире (квартал номеры һәм күмү участогы);

күмү урыны аның исеменә рәсмиләштерелгән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

11.4. Әлеге Нигезләмә кабул ителгәнче күмү турында таныклыкны рәсмиләштерү хакында гариза гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдә тапшырыла.

11.5. Күмү турында таныклык рәсмиләштерү хакындагы гаризага түбәндәге документлар кушып бирелә:

1) гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәсен кушып);

2) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, әгәр җирләү турында таныклык рәсмиләштерү хакында гариза белән гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать итсә, шулай ук гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

3) тиешле күмү урынында күмелгән үлгән кешегә карата үлем турында таныклык күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

4) көле салынган урна тиешле күмү урынына күмелгән үлгән кешегә карата мәетне яндыру турында белешмә күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхәне кушып);

5) тиешле күмү урынына җирләнгән үлгән кеше белән туганлык бәйләнешен раслый торган документлар яисә әлеге документларның нотариаль таныкланган күчермәләре.

Күмүләрне теркәү кенәгәсендә аның исеменә күмү урыны теркәлгән зат турында белешмәләр булганда, бу затка күмү турында таныклык әлеге пунктның 3-5 пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшырмыйча тутырыла.

11.6. Күмү турында таныклыкны рәсмиләштерүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) гаризаны карау өчен кирәкле документларның төп нөсхәләрен тапшырмау;

2) тапшырылган документларда чынбарлыгына объектив рәвештә инануны кыенлаштыра торган тулы булмаган, бозып күрсәтелгән яисә дөрес булмаган мәгълүмат булу;

3) сорала торган күмү урынына күмү турында таныклыкны элек башка затка бирү;

4) күмүләрне теркәү кенәгәсендә башкарылган күмү турында белешмәләрнең булмавы.

10.7. Күмү турында таныклык рәсмиләштерүдән баш тарту өчен нигезләр булганда, вәкаләтле орган, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, күмү турында таныклык рәсмиләштерүдән баш тартуны дәлилләп рәсмиләштерә.

11.8. Күмү турында таныклыкны рәсмиләштерүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, вәкаләтле орган күмү турында таныклыкны рәсмиләштерүне һәм бирүне гамәлгә ашыра.

11.9. Күмү турында таныклыкны рәсмиләштерү яисә күмү турында таныклыкны рәсмиләштерүдән баш тарту турындагы карар вәкаләтле орган тарафыннан гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне кабул ителә.

11.10. Күмү турында таныклыкны рәсмиләштерү яисә күмү турында таныклыкны рәсмиләштерүдән баш тарту турындагы карар гариза бирүчегә шәхсән кәгазьдәге документ рәвешендә бирелә.

## 12. Зиратларны карап тоту һәм керү кагыйдәләре

12.1. Җәмәгать зиратларын карап тоту вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.

Җәмәгать зиратларын карап тоту буенча подряд эшләренә агымдагы ремонт, җирләү билгеләнешендәге объектларны капиталь ремонтлау, җирләү бюджет акчалары хисабыннан башкарылган очракта, дәүләт саклавындагы каберләрне һәм һәйкәлләрне карап тоту, зират территориясен җыештыру һәм чүп-чарны чыгару керә;

12.2. Күмү өчен җаваплы гражданнар күмү урыны территориясендә чисталык һәм тәртип тәэмин итәргә, билгеләнгән урыннарда чүп-чарны җыярга, кабер участокларында үсемлек киртәләрне һәм чәчәкләрне карарга, кабер өсте корылмаларын (чардуган) вакытында ремонтларга, кабер калкулыкларын төзәтергә, һәйкәлләрне һәм чардуганнарны урнаштырырга, яңадан эшләргә һәм алып куярга бурычлы.

12.3. Күмү билгеләнешендәге объектлар территориясендә табутларны (үлгәннәрнең гәүдәләрен) ташу һәм күчерү өчен катафалка-арба, катафалка-чана, катафалка-носилка, ә урналарны күчерү өчен катафалка-носилка булырга тиеш.

12.4. Муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан зиратларда бердәм эш режимы билгеләнә.

Үлгәннәрне җирләү тәүлекнең якты вакытында башкарыла.

12.5. Җәмәгать зиратлары территориясендә килүчеләр тынлык һәм тәртип сакларга тиеш.

12.6. Җәмәгать зиратлары территориясендә килүчеләргә түбәндәгеләр тыела:

1) һәйкәлләргә, күмү урыннарына яисә җирләү билгеләнешендәге объектларга сәяси, идеологик, раса, милли яки дини нәфрәт, яисә дошманлык мотивлары буенча йә нинди дә булса социаль төркемгә карата нәфрәт яки дошманлык мотивлары буенча тиешле эчтәлекле язмалар яисә рәсемнәр ясарга;

2) җәмәгать зираты территориясен чүпләү;

3) агачларны һәм куакларны рөхсәтсез кисү;

4) этләрне йөртү, йорт хайваннарын көтү, кошлар аулау;

5) учаклар ягу;

6) ком, балчык казып алу, чирәмле туфрак кисү;

7) яшел утыртмаларны сындыру;

8) спиртлы эчемлекләр эчү һәм исерек хәлдә булу;

9) грунтны казу, төзелеш һәм башка материаллар запасларын калдыру;

10) бу максатлар өчен билгеләнмәгән урыннарда чүп-чар, сүтелгән иске кабер өсте корылмаларын (кабер ташларын), чардуганнарны өю;

11) үз белдегең белән кабер казу һәм җирләү;

12) зират ябылганнан соң, аның территориясендә булу.

12.7. Зиратларга массакүләм йөрү белән бәйле бәйрәмнәр вакытында вәкаләтле орган тарафыннан махсус эш һәм зиратларга бару режимнары кертелергә мөмкин.

## 13. Кабер өсте корылмалары (кабер ташлары), чардуганнар

13.1. Зиратларда кабер өсте корылмалары (кабер ташлары) һәм чардуганнар урнаштыру бары тик күмү урыннары чикләрендә генә рөхсәт ителә.

Урнаштырыла торган кабер өсте корылмаларның (кабер ташларының) һәм чардуганнарның күмү урыннарының чикләреннән чыгып торган яисә күршедәгесе өстендә асылынып торган өлешләре булмаска тиеш. Төрбәнең биеклеге өч метрдан артмаска тиеш. Чардуганның биеклеге бер метрдан артмаска тиеш.

Күмү урыннарыннан читтә урнаштырылган кабер өсте корылмалары (кабер ташлары) һәм чардуганнар җирле үзидарә органы билгеләгән тәртиптә алып атылырга тиеш.

13.2. Кабер өсте корылмаларын (кабер ташларын) һәм чардуганнарны кору, сүтү, ремонтлау, алмаштыру, күмү урыны аның исеменә теркәлгән зат (яисә аның язма йөкләмәсе буенча башка зат) тарафыннан паспорт яисә шәхесне таныклый торган башка документ, күмүне теркәү турында таныклык күрсәтелгәндә, вәкаләтле органның язма хәбәрнамәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.

13.3. Администрация тарафыннан кабер өстенә куелган һәр корылманы (кабер ташларын) теркәү һәм алмаштыру гамәлгә ашырыла, бу турыда кабер өсте корылмаларын (кабер ташларын) теркәү кенәгәсендә һәм күмүне теркәү турында тиешле таныклыкларда тиешле язма ясала.

Кабер өсте корылмасын (кабер ташы) кую, әлеге Нигезләмәнең 13.2 пунктында күрсәтелгән документлар күрсәтелгәндә, кабер өсте корылмаларын теркәү кенәгәсендә теркәлә.

13.4. Кабер өсте корылмаларын (кабер ташларын) теркәү кенәгәләре катгый хисаплылык документлары булып тора, даими саклау срогы булган эшләргә керә һәм муниципаль архивларның архив фондына даими саклауга тапшырыла.

13.5. Кабер өсте корылмаларындагы (кабер ташларындагы) язулар чыннан да шушы урында күмелгән үлгәннәр турындагы мәгълүматларга туры килергә тиеш.

13.6. Кабер өсте корылмаларыннан (кабер ташларыннан) һәм чардуганнардан файдалануның вакыты чикләнми, билгеләнгән тәртиптә объектны кешеләрнең сәламәтлегенә, күрше күмү урыннарының сакланышына куркыныч тудыра торган тузган дип тану очракларыннан тыш.

13.7. Зиратның архитектура-ландшафт проекты нигезендә соңыннан чардуганнар куймыйча җирләү каралган күмү урыннарында чардуганнар урнаштыру тыела.

13.8. Кабер өсте корылмаларын теркәү кенәгәсенә түбәндәге белешмәләр кертелә:

- үлгән кешенең фамилиясе, исеме, атасының исеме;
- кабер өсте корылмасының күренеше;
- кабер өсте корылмасын урнаштыру датасы;
- сектор номеры, кабер номеры;
- кабер өсте корылмасының материалы һәм үлчәмнәре;
- кабер өсте корылмасын урнаштыру датасы;
- күмү өчен җаваплы затның фамилиясе һәм инициаллары.

## 14. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

Әлеге Нигезләмәне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә барлыкка килә торган бәхәсләр судтан тыш һәм суд тәртибендә хәл ителә.

## 15. Җирләү һәм күмү эше өлкәсендәге законнарны бозган өчен җаваплылык

Җирләү һәм күмү эше өлкәсендә гамәлдәге законнар нигезләмәләрен бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы булалар.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 03 мартының 12 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре территориясендә урнашкан зиратлар исемлеге

| Т/б № | Җәмәгать зираты исеме | Җәмәгать зиратының урнашу урыны (адресы) |
|---|---|---|
| 1 | Христиан зираты (яңа) | ТР, Кукмара муниципаль районы, Кукмара ш., Ленин ур. |
| 2 | Мөселман зираты (яңа) | ТР, Кукмара муниципаль районы, Кукмара ш., Ленин ур. |
| 3 | Мөселман зираты (яңа) | ТР, Кукмара муниципаль районы, Кукмара ш., Ленин ур. |
| 4 | Христиан зираты (иске) | ТР, Кукмара муниципаль районы, Кукмара ш., Эшчеләр тыкрыгы ур. |
| 5 | Мөселман зираты (иске) | ТР, Кукмара муниципаль районы, Кукмара ш., Мичурин ур. |
| 6 | Мөселман зираты (Туеш) | ТР, Кукмара муниципаль районы, Кукмара ш., Гагарин ур. |

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 03 мартының 12 номерлы Карары белән расланган

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтү максатларында кулланыла торган документлар формалары

Форма 1

___________________________________________

___________________________________________

(җирле үзидарәнең җирләү һәм күмү эше өлкәсендә вәкаләтле органы исеме)

___________________________________________

